ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

## КАРАР

10 декабрь 2024 ел № 17

**Арча муниципаль районы "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы, "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2022 елның 04 августындагы 54 номерлы Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карары нигезендә 18.11. 2024 N9, 19.11. 2024 N10, 19.11.2024 N11, 20.11.2024 N12, 21.11. 2024 N 13, 25.11.2024 N14, 26.11.2024 №15, 27.11.2024 №16 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Иске Кырлай авылы, Узәк ур., 12А, ТР, Арча районы, Тубән Мәтәскә авылы, Тукай ур., 2 йорт.
3. "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның

үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында" 2023 елның 14 декабрендәге 20 номерлы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны өстемә алам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин

Иске Кырлай авыл җирлеге
башкарма комитетының
10.12.2024, № 17
карарына 1 нче кушымта

**Арча муниципаль районы "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районы "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын Арча муниципаль районы "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, 2025 елның 27 февраленә кадәр түлиләр.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналар, ир яки хатын, балигъ булган балалар).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а)көндезге уку формасы буенча укучы студентлар,

б)1 төркем инвалидлар,

в) балачактан инвалидлар,

г) сугыш хәрәкәтләре ветераннары,

д) Чернобыль АЭС һәлакәтен бетерүдә катнашканнар,

е) 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (ата-анасының, иренең/хатынының, балаларының) вафат булуы,

б) янгын яисә башка табигый бәла-казалар аркасында зыян килү гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерү бирелә.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында гражданнарга хәбәр итү бланкы (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгару, Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куеп тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Арча муниципаль районы "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

8. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

10. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгән дә, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Иске Кырлай авыл җирлеге
башкарма комитетының
10.12.2024, № 17
карарына 2 нче кушымта

**Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә N ______________**

Түләүченең Ф.И.А.и______________________________________________

Адресы:_________________________________________________________

Нигезе__________________________________________________________

Сезгә ______________________ чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр түләү____________________________________ суммада _____________ сум түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:__________________________________________

алучының банкы БИК __________________________

Сч. N _____________________________________

Алучы Сч. N ___________________________

ИНН ________________________________________

КПП ________________________________________

КБК _________________ОКАТО __________________

Түләүнең билгеләнеше ________________________________________________________

Җитәкче _________________ _____________________________________

М. у. (имза) (имзаның аңлатмасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисем сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

"Иске Кырлай авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә №__
суммада ________________ сум

Түләүченең Ф. и.а.и. ________________________________________________

Адресы: ________________________________________________________

Алдым "___" _______________ 20__ ел ___________________________________

(түләүченең имзасы /ФИАи)

Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өзек тамыр тутырыла һәм Иске Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитетында кала